**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# О Совете при Раисе Республики Татарстан по вопросам повышения качества жизни граждан, проживающих на территории Республики Татарстан

В целях реализации на территории Республики Татарстан Национальной социальной инициативы, внедрения регионального социального стандарта и повышения уровня удовлетворенности жителей Республики Татарстан качеством социальных услуг **постановляю**:

1. Образовать Совет при Раисе Республики Татарстан по вопросам повышения качества жизни граждан, проживающих на территории Республики Татарстан.

2. Утвердить Положение о Совете при Раисе Республики Татарстан по вопросам повышения качества жизни граждан, проживающих на территории Республики Татарстан (приложение № 1), и его состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
26 июня 2023 года
№ 431

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «26» июня 2023 года

№ 431

**Положение**
**о Совете при Раисе Республики Татарстан по вопросам повышения качества жизни граждан, проживающих на территории Республики Татарстан**

## I. Общие положения

1.1. Совет при Раисе Республики Татарстан по вопросам повышения качества жизни граждан, проживающих на территории Республики Татарстан (далее – Совет), является коллегиальным совещательным органом, образованным для обеспечения взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления) и организаций при рассмотрении вопросов, связанных с развитием человеческого капитала, повышением уровня удовлетворенности граждан качеством социальных услуг и совершенствованием государственной политики в указанной сфере в Республике Татарстан.

1.2. Деятельность Совета направлена на рассмотрение вопросов в сферах здравоохранения, образования, занятости и социальной защиты населения, молодежной политики, развития благоприятной городской среды (далее – социальная сфера).

1.3. В своей деятельности Совет руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, указами и распоряжениями Президента Российской Федерации, постановлениями и распоряжениями Правительства Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, указами и распоряжениями Раиса Республики Татарстан, постановлениями и распоряжениями Кабинета Министров Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

## II. Основные задачи Совета

Основными задачами Совета являются:

формирование предложений по приоритетам реализации государственной политики в социальной сфере Республики Татарстан;

подготовка предложений по совершенствованию законодательства Республики Татарстан в социальной сфере;

рассмотрение приоритетных проектов в социальной сфере Республики Татарстан и результатов их реализации;

участие в анализе результатов рейтинга качества жизни граждан, формируемого автономной некоммерческой организацией «Агентство стратегических инициатив по продвижению новых проектов», подготовке предложений по улучшению позиций Республики Татарстан в указанном рейтинге на основании мнения граждан;

содействие в разработке и внедрении в Республике Татарстан регионального социального стандарта;

организация межведомственного и межуровневого взаимодействия между органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, а также взаимодействия с юридическими и физическими лицами по вопросам разработки и внедрения на территории Республики Татарстан комплекса управленческих практик и решений для повышения качества и доступности услуг в социальной сфере.

## III. Права Совета

Для выполнения возложенных задач Совет вправе:

рассматривать вопросы, связанные с улучшением качества жизни граждан;

запрашивать и получать в установленном порядке необходимую информацию от органов государственной власти, органов местного самоуправления, общественных объединений, организаций;

приглашать на свои заседания должностных лиц органов государственной власти, органов местного самоуправления, представителей общественных объединений, организаций;

привлекать в установленном порядке для осуществления информационно-аналитических и экспертных работ научные, образовательные и иные организации, а также ученых и экспертов;

образовывать экспертные, консультативные, рабочие группы в порядке, предусмотренном федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан и настоящим Положением;

принимать решения по результатам работы Совета и контролировать их исполнение.

## IV. Порядок формирования и деятельности Совета

4.1. Состав Совета утверждается Раисом Республики Татарстан.

4.2. В состав Совета входят председатель Совета, заместитель председателя Совета, секретарь Совета и иные члены Совета.

4.3. Председателем Совета является Раис Республики Татарстан. В отсутствие председателя Совета либо по его поручению функции председателя Совета выполняет заместитель председателя Совета.

4.4. Председатель Совета:

а) руководит работой Совета, определяет и утверждает повестку, дату, время и место проведения его заседаний;

б) представляет Совет во взаимоотношениях с органами государственной власти, органами местного самоуправления, организациями;

в) распределяет обязанности между членами Совета;

г) утверждает протоколы заседаний Совета и подписывает другие документы Совета;

д) координирует реализацию решений Совета.

4.5. Секретарь Совета:

а) созывает очередные и внеочередные заседания Совета и организует их проведение;

б) обеспечивает подготовку планов работы Совета, формирует повестку его заседаний, организует подготовку материалов к заседаниям Совета;

в) обеспечивает ведение протоколов заседаний Совета и их оформление, подписывает протоколы заседаний Совета;

г) обеспечивает направление решений Совета его членам и доведение решений Совета до сведения органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и иных заинтересованных лиц в части, их касающейся;

д) организует работу по обобщению и анализу информации, документов и материалов, необходимых для осуществления деятельности Совета, поступивших от органов государственной власти, органов местного самоуправления, организаций;

е) информирует членов Совета о дате, времени и месте проведения, повестке очередного заседания Совета, обеспечивает их необходимыми справочно-информационными материалами.

4.6. Члены Совета:

а) вносят предложения по плану работы Совета, повестке его заседаний и порядку обсуждения вопросов;

б) участвуют в подготовке материалов к заседаниям Совета, а также проектов его решений;

в) содействуют реализации решений Совета.

4.7. Члены Совета имеют право знакомиться с представленными в Совет материалами.

4.8. Члены Совета участвуют в его заседаниях без права замены. В случае невозможности присутствия члена Совета на его заседании он обязан заблаговременно известить об этом председателя Совета.

4.9. Материалы по вопросам, планируемым к рассмотрению на заседаниях Совета, рассылаются членам Совета секретарем Совета не позднее пяти рабочих дней до даты проведения заседания Совета.

4.10. Совет вправе формировать из числа членов Совета рабочие группы (подгруппы), экспертные советы по направлениям своей деятельности.

К участию в работе рабочих групп (подгрупп), экспертных советов привлекаются ученые, эксперты из числа специалистов по профилю рассматриваемой проблемы, представители органов государственной власти, органов местного самоуправления, организаций. Составы рабочих групп (подгрупп) утверждаются решением Совета.

4.11. Организационно-техническое и информационное обеспечение деятельности Совета осуществляет Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан.

4.12. Деятельность Совета осуществляется в соответствии с годовыми планами, утверждаемыми председателем Совета.

4.13. При необходимости вопросы, не нашедшие отражения в плане работы Совета, вносятся на рассмотрение Совета во внеплановом порядке.

4.14. Заседания Совета проводятся по мере необходимости, но не реже двух раз в год. Заседания Совета проводятся как в очном формате, так и в режиме видео-конференц-связи.

4.15. При необходимости на заседания Совета приглашаются компетентные в рассматриваемых Советом вопросах представители органов государственной власти, органов местного самоуправления, организаций.

4.16. Заседание Совета считается правомочным, если на нем присутствует более половины от общего числа членов Совета.

4.17. Решения Совета принимаются открытым голосованием и считаются принятыми, если они поддержаны простым большинством участвующих на заседании членов Совета. При равенстве голосов решающим является голос председателя Совета или его заместителя, председательствующего на заседании.

При принятии решений по организационным вопросам деятельности Совета возможно тайное голосование с использованием опросных листов.

4.18. Решения Совета оформляются протоколом, который подписывается секретарем Совета и утверждается председательствующим на заседании Совета. Решения Совета направляются членам Совета и доводятся до сведения органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и иных заинтересованных лиц в части, их касающейся.

4.19. Председатель Совета, заместитель председателя Совета, секретарь Совета и члены Совета работают в Совете на общественных началах.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «26» июня 2023 года
№ 431

**Состав**
**Совета при Раисе Республики Татарстан по вопросам повышения качества жизни граждан, проживающих на территории Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Раис Республики Татарстан, председатель Совета |
| Фазлеева Лейла Ринатовна | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя Совета |
| Абдреева Юлия Ивановна | заместитель министра труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан, секретарь Совета |
| Айзатуллин Марат Мансурович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Бадреев Ильдар Фоатович | начальник Управления социального развития Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Вавилов Владимир Владимирович | депутат Государственного Совета Республики Татарстан, председатель правления Регионального общественного благотворительного фонда помощи детям, больным лейкемией, Республики Татарстан имени Анжелы Вавиловой (по согласованию) |
| Валеева Зиля Рахимьяновна | председатель Общественной палаты Республики Татарстан (по согласованию) |
| Волынец Ирина Владимировна | Уполномоченный по правам ребенка в Республике Татарстан (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Загретдинов Адель Линнарович | директор Благотворительного фонда помощи детям с ограниченными возможностями здоровья «Сила в детях», автономной некоммерческой организации для людей с повышенными потребностями здоровья «Дарим ангелам радость», председатель Региональной общественной организации Республики Татарстан «Союз отцов» (по согласованию) |
| Зарипов Раушан Булатович | исполняющий обязанности начальника Управления по вопросам здравоохранения, спорта и формирования здорового образа жизни Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Зарипова Эльмира Амировна | министр труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан |
| Захарова Светлана Михайловна | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по социальной политике (по согласованию) |
| Ильдарханова Чулпан Ильдусовна | начальник обособленного структурного подразделения государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан» «Центр семьи и демографии Академии наук Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Иштиряков Хабир Газизович | председатель Региональной общественной организации ветеранов (пенсионеров) Республики Татарстан (по согласованию) |
| Кузнецов Артем Викторович | член комиссии Общественной палаты Республики Татарстан по социальным вопросам, благотворительности и развитию некоммерческого сектора, председатель Региональной общественной организации «Многодетные семьи Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Миннуллин Марсель Мансурович | министр здравоохранения Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Мишина Любовь Николаевна | председатель правления Регионального отделения Общероссийской общественной организации «Союз пенсионеров России» по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Сабурская Сария Харисовна | Уполномоченный по правам человека в Республике Татарстан (по согласованию) |
| Садыков Ринат Наильевич | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Созинов Алексей Станиславович | депутат Государственного Совета Республики Татарстан, ректор федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский государственный медицинский университет» Министерства здравоохранения Российской Федерации (по согласованию) |
| Фазылов Ринат Рафаэлевич | руководитель исполнительного комитета Регионального отделения Общероссийского общественного движения «НАРОДНЫЙ ФРОНТ «ЗА РОССИЮ» в Республике Татарстан (по согласованию) |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы совет турында

Татарстан Республикасы территориясендә Илкүләм социаль инициативаны гамәлгә ашыру, төбәк социаль стандартын кулланышка кертү, Татарстан Республикасы халкының социаль хезмәтләр сыйфатыннан канәгатьлеге дәрәҗәсен күтәрү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы советны төзергә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы совет турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 26 июнь
№ 431

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «26» июнендәге
431 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы совет турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча совет (алга таба – Совет) кеше капиталы үстерү, гражданнарның социаль хезмәтләр сыйфатыннан канәгатьлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм Татарстан Республикасында әлеге өлкәдә дәүләт сәясәтен камилләштерү белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшергәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары) һәм оешмаларның бергәләп эшчәнлек алып баруын тәэмин итү өчен төзелгән коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

1.2. Совет эшчәнлеге сәламәтлек саклау, мәгариф, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, яшьләр сәясәте, уңайлы шәһәр мохитен киңәйтү өлкәләрендә мәсьәләләрне карап тикшерүгә юнәлдерелгән.

1.3. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Советның төп бурычлары

Советның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының социаль өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның өстенлекле юнәлешләре буенча тәкъдимнәр булдыру;

социаль өлкәдә Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасының социаль өлкәсендә өстенлекле проектларны һәм аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен карап тикшерү;

«Яңа проектларны таныту буенча стратегик инициативалар агентлыгы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы тарафыннан формалаштырыла торган гражданнарның тормыш сыйфаты рейтингы йомгакларын анализлауда, гражданнар фикеренә нигезләнеп, әлеге рейтингта Татарстан Республикасының тоткан урынын яхшырту буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасында төбәк социаль стандартын эшләүгә һәм кулланышка кертүгә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы территориясендә социаль өлкәдә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту һәм алардан файдалана алу мөмкинлекләрен арттыру өчен идарәчел практикалар һәм карарлар комплексын эшләү һәм кулланышка кертү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара һәм төрле дәрәҗәдәге хезмәттәшлекне, шулай ук юридик һәм физик затлар белән хезмәттәшлекне оештыру.

## III. Советның хокуклары

Совет үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерергә;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, оешмалардан тиешле мәгълүматны соратып алырга;

үз утырышларына дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнар вазыйфаи затларын, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар вәкилләрен чакырырга;

мәгълүмат-аналитика һәм эксперт эшләрен башкару өчен билгеләнгән тәртиптә фән, мәгариф оешмаларын һәм башка оешмаларны, шулай ук галимнәрне һәм экспертларны җәлеп итәргә;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә эксперт, консультация, эш төркемнәре төзергә;

Совет эше нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итәргә һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга.

## IV. Советны формалаштыру һәм аның эшчәнлек алып бару тәртибе

4.1.Совет составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

4.2. Совет составына Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, Совет секретаре һәм Советның башка әгъзалары керә.

4.3. Совет рәисе булып Татарстан Республикасы Рәисе тора. Совет рәисе булмаганда яисә аның йөкләве буенча аның функцияләрен Совет рәисе урынбасары башкара.

4.4. Совет рәисе:

а) Совет эшенә җитәкчелек итә, аның утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

б) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар белән үзара эшчәнлектә Совет вәкиле буларак катнаша;

в) Совет әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

г) Совет утырышлары беркетмәләрен раслый һәм Советның башка документларына кул куя;

д) Совет карарларының үтәлүен координацияли.

4.5. Совет секретаре:

а) Советның чираттагы һәм чираттан тыш утырышларын чакыра һәм аларны уздыруны оештыра;

б) Советның эш планнарын әзерләүне тәэмин итә, аның утырышларының көн тәртибен формалаштыра, Совет утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

в) Совет утырышлары беркетмәләрен алып баруны һәм аларны рәсмиләштерүне тәэмин итә, Совет утырышлары беркетмәләренә кул куя;

г) Совет карарларын Совет әгъзаларына юллауны һәм Совет карарларының аларга кагылышлы булган өлешләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм башка кызыксынган затларга хәбәр итүне тәэмин итә;

д) Совет эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан килгән мәгълүматны, документларны һәм материалларны гомумиләштерү һәм анализлау эшен оештыра;

е) Совет әгъзаларына Советның чираттагы утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны, көн тәртибе турында мәгълүмат юллый, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә.

4.6. Совет әгъзалары:

а) Советның эш планы, аның утырышларының көн тәртибе һәм мәсьәләләр буенча фикер алышу турында тәкъдимнәр бирә;

б) Совет утырышларына материаллар, аның карарлары проектларын әзерләүдә катнаша;

в) Совет карарларын үтәүгә булышлык итә.

4.7. Совет әгъзалары Советка тәкъдим ителгән материаллар белән танышырга хокуклы.

4.8. Совет әгъзалары аның утырышларында үзләренә алмашка башка кеше җибәрү хокукына ия булмыйча катнаша. Совет әгъзасының утырышта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, ул бу хакта Совет рәисенә алдан хәбәр итәргә тиеш.

4.9. Совет утырышларында карап тикшерү планлаштырыла торган мәсьәләләр буенча материаллар Совет әгъзаларына Совет секретаре тарафыннан Совет утырышын уздыру датасына кадәр кимендә биш эш көне алдан юллана.

4.10. Совет үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча Совет әгъзалары кергән эш төркемнәре (ярдәмче төркемнәр), эксперт советлары төзергә хокуклы.

Карап тикшерелә торган мәсьәлә юнәлеше буенча белгечләр арасыннан галимнәр, экспертлар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар вәкилләре эш төркемнәре (ярдәмче төркемнәр), эксперт советлары эшендә катнашуга җәлеп ителә. Эш төркемнәре (ярдәмче төркемнәр) составлары Совет карары нигезендә раслана.

4.11. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм мәгълүмат белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы башкара.

4.12. Совет эшчәнлеге Совет рәисе тарафыннан раслана торган еллык планнар нигезендә алып барыла.

4.13. Советның эш планына кертелмәгән мәсьәләләр кирәк булганда чираттан тыш тәртиптә Советта карап тикшерүгә тапшырыла.

4.14. Совет утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә елга ике тапкыр уздырыла. Совет утырышлары турыдан-туры катнашу форматында да, шулай ук видео-конференц-элемтә режимында да уздырыла.

4.15. Кирәк булганда, Совет утырышына дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның Советта карап тикшерелә торган мәсьәләләр белән шөгыльләнүче вәкилләре чакырыла.

4.16. Совет утырышы, әгәр анда Совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы катнашса, гамәлгә хокуклы санала.

4.17. Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм утырышта катнашучы Совет әгъзаларының гади күпчелеге аны хуплап тавышы бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, Совет рәисе яисә Совет рәисенең утырышта рәислек итүче урынбасары тавышы хәлиткеч дип санала.

Совет эшчәнлегенә кагылышлы оештыру мәсьәләре буенча карарлар кабул иткәндә сораштыру кәгазьләре ярдәмендә яшерен тавыш бирү уздырылырга да мөмкин.

4.18. Совет карарлары Совет секретаре тарафыннан кул куела һәм Совет утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана торган беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Совет карарлары Совет әгъзаларына юллана һәм аларга кагылышлы булган өлешләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм башка кызыксынган затларга җиткерелә.

4.19. Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, Совет секретаре һәм Совет әгъзалары Совет эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

___________

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «26» июнендәге
431 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы совет составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Рәисе, Совет рәисе |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Совет рәисе урынбасары |
| Әбдриева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, Совет секретаре |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Вавилов Владимир Владимирович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасының лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итү буенча Анжела Вавилова исемендәге төбәк иҗтимагый хәйрия фонды идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Волынец Ирина Владимировна | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Заһретдинов<br>Адел Линнар улы | «Балаларда көч» сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга ярдәм итү хәйрия фонды, «Дарим ангелам радость» сәламәтлегенә зур игътибар соралган кешеләр өчен автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры, Татарстан Республикасының «Аталар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Захарова<br>Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Илдарханова<br>Чулпан Илдус кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге» башлыгы (килешү буенча) |
| Иштирәков<br>Хәбир Газиз улы | Татарстан Республикасының ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Кузнецов<br>Артем Викторович | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль мәсьәләләр, хәйриячелек һәм коммерциячел булмаган секторны үстерү буенча комиссиясе әгъзасы, «Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Миңнуллин<br>Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |

| | |
|---|---|
| Мишина<br>Любовь Николаевна | «Россия пенсионерлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Сабурская<br>Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Созинов<br>Алексей Станиславович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Фазылов<br>Ринат Рафаэль улы | Татарстан Республикасында «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәте төбәк бүлекчәсе төбәк башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |